**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

19.03.2020 № 129

**О введении режима повышенной готовности для органов управления и сил территориальной подсистемы предупреждения и ликвидации чрезвычайных ситуаций Республики Татарстан**

В связи с угрозой распространения в Республике Татарстан новой коронавирусной инфекции (2019-nCoV), в соответствии с Федеральным законом от 21 декабря 1994 года № 68-ФЗ «О защите населения и территорий от чрезвычайных ситуаций природного и техногенного характера», Законом Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 62-ЗРТ «О защите населения и территорий от чрезвычайных ситуаций»:

1. Ввести для органов управления и сил территориальной подсистемы предупреждения и ликвидации чрезвычайных ситуаций Республики Татарстан с 19 марта 2020 года и до особого распоряжения режим повышенной готовности и установить региональный (межмуниципальный) уровень реагирования.

2. Комиссии по предупреждению и ликвидации чрезвычайных ситуаций и обеспечению пожарной безопасности Республики Татарстан обеспечить:

координацию деятельности органов управления и сил территориальной подсистемы предупреждения и ликвидации чрезвычайных ситуаций Республики Татарстан при функционировании в режиме повышенной готовности;

согласованность действий органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления и организаций при реализации настоящего распоряжения.

3. Кабинету Министров Республики Татарстан обеспечить принятие мер по предотвращению завоза и распространения в Республике Татарстан новой коронавирусной инфекции (2019-nCoV).

4. Контроль за реализацией настоящего распоряжения возложить на Премьер-министра Республики Татарстан.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

19.03.2020 № 129

**Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен югары дәрәҗәдә әзерлек режимы кертү турында**

Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе (2019-nCoV) таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Халыкны һәм территорияләрне табигать һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен, махсус боерык чыкканга кадәр, 2020 елның 19 мартыннан югары дәрәҗәдә әзерлек режимы кертергә һәм төбәк (муниципальара) дәрәҗәсендә чаралар күрелергә тиешлеген билгеләргә.

2. Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

югары дәрәҗәдә әзерлек режимында эшләгәндә Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре эшчәнлеген координацияләүне;

әлеге боерыкны үтәгәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның гамәлләрен килештерүне.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасына яңа коронавирус инфекциясе (2019-nCoV) үтеп керүен һәм таралуын кисәтү буенча чаралар кабул итүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы
Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ